СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

26.10.2023 Баулы шәһәре № 226

Баулы муниципаль районы Советының
2022 елның 27 октябрендәге 141 номерлы
“Баулы муниципаль районы территориясендә
автомобиль транспорты, шәһәр транспорты,
җир өсте электр транспорты һәм
юл хуҗалыгында муниципаль контроль
турында Нигезләмәне раслау турында”
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 10 мартындагы 336 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карарына ярашлы, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Баулы муниципаль районы Советының 2022 елның 27 октябрендәге 141 номерлы “Баулы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспорты, шәһәр транспорты, җир өсте электр транспорты һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау турында” карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) муниципаль контроль объектында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл транспортында, утыз календарь көн эчендә торак пункт чикләрендә һәм (яки) бер үк җирле әһәмияттәге юлда ике һәм аннан да күбрәк юл-транспорт һәлакәте;

2) контрольдә тотылган затның машина йөртүчеләре тарафыннан бер календарь ел дәвамында даими пассажирлар йөртү маршрутында автомобиль транспорты, шәһәр, җир өсте, электр транспорты белән йөрү кагыйдәләрен бозу очракларының, алдагы календарь ел белән чагыштырганда, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша

Таатарстан Республика буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан бирелгән мәгълүматлар нигезендә биш процентка һәм аннан да күбрәккә арту.

3) Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирелгән мәгълүматлар нигезендә, бер календарь ел эчендә юл инфраструктурасы объектында юл-транспорт һәлакәтләре санының ике һәм аннан да күбрәк тапкырга артуы.

4) узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, контрольдә тотылган кешенең кулында булган яки файдаланган юл участогында календарь айда юл-транспорт һәлакәтләре санының биш процентка артуы (әмма ким дигәндә өч бозуга).

5) хисап елы дәвамында юлның бер участогында яки юллар һәм урамнар киселешендә кешеләр зыян күргән яки яраланган, юл шартлары белән бәйле рәвештә бер төр юл-транспорт һәлакәтенең барлыкка килүенең өч һәм аннан да күбрәк фактын ачыклау.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының икътисади үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
Район Советы рәисе И.И. Гозәеров